**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2345**
**06.05.2022**

Башкарма комитетның «2022 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондының торак урыныннан файдалану өчен түләү (наем өчен түләү), торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» 2022 елның 19 гыйнварындагы 162 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясының 3, 4 өлешләре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы Карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 31, 36 пунктлары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2017 елның 26 декабрендәге 8125 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу килешүләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү турында нигезләмә, 2022 елга лифтларга агымдагы ремонт һәм техник хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләргә түләү күләмен (бәя) билгеләү турында тәкъдимне формалаштырганда исәп-хисапларны икътисадый нигезләү буенча 2021 елның 8 ноябрендәге 21/15-ЭЭ номерлы бәйсез экспертиза хисабы, 2022 елга йорт эчендәге электр челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт буенча хезмәтләргә түләү күләмен (бәя) билгеләү турында тәкъдим формалаштырганда исәп-хисапларны икътисадый нигезләү буенча 2021 елның 28 ноябрендәге 21/18, 19, 20-ЭЭ номерлы бәйсез экспертиза хисабы, 2022 елга Яр Чаллы шәһәре торак йортларында янгынга каршы автоматика һәм төтен бетерү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт буенча хезмәтләргә түләү күләмен (бәя) исәпләгәндә чыгымнарны икътисадый нигезләү буенча 2022 елның 22/23-ЭЭ номерлы бәйсез экспертиза хисабы, 2022 елга Яр Чаллы шәһәре буенча домофоннарга (подъезд ишекләренең сөйләшү-йозак җайланмаларына) техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау буенча хезмәтләргә түләүнең иң чик күләмен (бәясен) билгеләү буенча тәкъдимне исәпләү буенча бәйсез экспертиза, 2022 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондының дератизация һәм дезинсекция хезмәтләренә түләү күләмен (бәя) исәпләгәндә чыгымнарны икътисадый нигезләү буенча 2022 елның 18 апрелендәге 22/24-ЭЭ номерлы хисабы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2022 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондының торак урыныннан файдалану өчен түләү (наем өчен түләү), торак урыннарын карап тоту өчен

түләү күләме турында» 2022 елның 19 гыйнварындагы 162 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2, 3.1, 3.2, 3.4, 4.2, 4.3, 4.9 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № т/б | Түләү исеме | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | 01.05.2022 елдан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 2. | Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 3,25 |
| 3. | Гомуми файдалану урыннарының санитар торышы, шул исәптән: | | |
| 3.1. | - йорт эчендәге гомуми файдалану урыннарын җыештыру | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 2,15 |
| 3.2. | - йорт яны территориясен җыештыру | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 3,30 |
| 3.4. | - дератизация (дезинсекция) | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 0,21 |
| 4. | Төзелеш корылмаларын һәм биналарның инженерлык системаларын ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү, шул исәптән: | | |
| 4.2. | - лифтлар | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 3,54 |
| 4.3. | - йорт эчендәге электр челтәрләре һәм электр җиһазлары | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 0,95 |
| 4.9. | - янгынга каршы автоматика системасы (хезмәт күрсәтелгән очракта) | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 1,15 |

2) 4.5 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Ф.Ш. Салахов